**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2023елның 1 июне** **70-РС номер**

# КАРАР

**«2022-2024 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе турында»2022 елның 5 декабрендәге 92-РС номерлы Совет карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын яхшырту максатыннан карар кабул итте:

1. «2022-2024 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе турында " 2022 елның 5 декабрендәге 92-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, 4 бүлеген тулыландырырга:

- Татарстан Республикасында кунакханә бизнесының үсеше тигез түгел. Күп санлы урнаштыру чаралары Казан шәһәрендә тупланган, район территориясендә бу төр хезмәтләр аз үсеш алган. SPA белән кунакханә комплексы төзү мәсьәләсен хәл итү максатыннан 16:24:000000:822 кадастр номеры белән 1905 кв.м. мәйданлы урман фонды җирләреннән җир участогы сайлап алынган. Матюшино авыл җирлеге территориясендә SPA белән кунакханә комплексы төзү туристларны өстәмә җәлеп итүгә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, авыру дәрәҗәсен киметүгә, җирле халыкның һәм туристларның иммунитетын ныгытуга ярдәм итәчәк.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лаеш муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**

**Советы  Рәисе** **И.Ф. Зарипов**